Исполнительный комитет
Мунайкинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Республика Татарстан
423652 д.Мунайка ,ул.Строителей, д.12
Тел.(885549)3-58-09

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл башкарма комитеты
423652 Монай авылы, Тезучелэр ур.12
нче йорт
Тел.(885549)3-58-09

КАРАР

15 июль 2025 ел № 21

Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге территориясендә
терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында

"Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварендагы 7-ФЗ номерлы, "Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән яктырту җайланмалары, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегендә яшәүче терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урынын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Менделеевск районы Монай авылы, Ленин урамы, 54 йорт, Монай авыл башкарма комитеты территориясе.

2. Күпфатирлы йортларда биналарның хуҗалары, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмөшле лампалар кулланучыларда, файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән яктырту җайланмалары, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән файдаланылган терекөмешле лампаларны туплану урыннары, шул исәптән күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, терекөмешле лампалар туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, бу күпфатирлы йортлардагы биналар милекчеләре,

яллаучылары, файдаланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә,

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Монай авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов